| | |
|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 21 сентябрь № 694

г. Казань

2016 елга «Бәхетле балачак» балалар үзәге» балаларга өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елга түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

өстәмә гомуми белем бирүче гомуми үстерү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

өстәмә гомуми белем бирүче гомуми үстерү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең норматив күләмнәрен;

өстәмә гомуми белем бирүче гомуми үстерү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең норматив күләменә карата төзәтү коэффициентын.

2. Үз көчен югалаткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасының балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге дәүләт мәгариф оешмалары һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күпьюнәлешле дәүләт мәгариф оешмалары норматив чыгымнарын раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 793 нче карарын;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 ел, 20 август, 609 нчы карарын.

3. Бу карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 21 сентябрь,
694 нче карары белән
расланды

Өстәмә гомуми белем бирүче гомуми үстерү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Норматив чыгымнар, 1 укучыга елына сум | | |
|---|---|---|---|
| | укуның беренче елы | укуның икенче елы | укуның өченче һәм шуннан соңгы еллары |
| Сәнгати-эстетик | 3 742 | 6 930 | 8 316 |

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 21 сентябрь,
694 нче карары белән
расланды

Өстәмә гомуми белем бирүче гомуми үстерү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең норматив күләмнәре

| Учреждение исеме | Елына хезмәтләр саны, кеше |
|---|---|
| «Бәхетле балачак» балалар үзәге» балаларга өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе | 450 |

____________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 21 сентябрь,
694 нче карары белән
расланды

Өстәмә гомуми белем бирүче гомуми үстерү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең норматив күләменә карата төзәтү коэффициенты

| Учреждение исеме | Төзәтү коэффициенты |
|---|---|
| «Бәхетле балачак» балалар үзәге» балаларга өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе | 1,3717 |

---

F:\KARAR\2015\694-1.docx